КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 апрель г.Казань № 260

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче, 2020 ел, 27 март, 223 нче, 2020 ел, 30 март, 234 нче, 2020 ел, 31 март, 240 нчы, 2020 ел, 03 апрель, 252 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$2^1$ пунктта «Туктатып торырга» сүзен «Туктатып торырга (чикләргә)» сүзләренә алмаштырырга;

$7^1$ пункттан соң «таралмый» сүзеннән соң «кичектергесез нотариаль гамәлләр кылучы нотариуслар һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүче затлар» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру буенча чаралар хакында» үзгәрешләр кертү хакында 2020 ел, 31 нче март, 240 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Махсуслаштырылган сервиста теркәлү өчен граждан 2590 номерына «теркәлү#паспорт сериясе һәм номеры»* тексты белән түләүсез СМС-хәбәр җибәрә (мәсәлән: теркәү#9219632506).»;

астөшермәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Паспортның сериясе һәм номеры пробелларсыз һәм билгеләрсез күрсәтелә».

3. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин